РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет**
***Старобарышевского***
***сельского поселения***
Камско-Устьинского
муниципального района

422835, с. Старое Барышево, ул.Центральная, 15
тел.(884377)30-3-18, ИНН/КПП 1622004570 / 162201001
ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кама Тамагы
муниципаль районы
***Иске Барыш***
***авыл җирлеге***
**Башкарма комитеты**

422835, Иске Барыш авылы, Үзэк урамы, 15
тел.(884377)30-3-18, ИНН / КПП 1622004570 / 162201001
ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

**КАРАР**

«5 »декабрь 2019ел № 33

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенең Иске Барыш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенә кергән Иске Барыш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенынын 1 этабын 2019 елнын 17 нче декабренэ 10.00 сэгатькэ билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенә кергән Иске Барыш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенынын 2 этабын 2019 елнын 18 нче декабренэ 13.00 сэгатькэ билгеләргэ

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндэге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенә кергән Иске Барыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

* Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
* Җирлек торак пунктлары чикләрендә территорияләрне төзекләндерүне оештыру;
* Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлүне җирлекләр чикләрендә оештыру:

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен авыл җирлегендә яшәүчеләрнең исемлеген бүлү тәртибе:
   - икенче этапта беренче этапта катнаша алмаган кешеләр катнаша.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Иске Барыш авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Р. Җиһаншин**